КӘГАЗЬ БОТКАСЫ

Табибларны медицинага карамаган эшләрдән азат итмәкчеләр

> 2

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«Икътисадта кискен үзгәрешләр килеп чыкмаса, бюджет үтәләчәк»

> 3

СЕРЕ НИДӘ?

Татарстанда яшәүче төрле милләт вәкилләре – дус-тату яшәү, бердәмлек турында

> 4

ФАЙДАЛЫ ЧАКРЫМНАР

Спортчы Валерия Захарова йөгереп ял итә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 161 (29128) | Чәршәмбе | 1 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ЯНГЫН ЯЛГЫШЛАРНЫ КИЧЕРМИ

Борчыган мәсьәлә

Янгын сүндерүчеләр ягу сезонында янгыннар саны артуын әйтә. Ел башыннан илдә бары тик мич җылыту аркасында гына да 16 мең янгын чыккан. Мондый фаҗигаләрдән ничек сакланырга? Нәрсәгә игътибарлы булырга? Без шул турыда белештек.

mchs.gov.ru

Торак йортларда янгыннарны кисәтү максатыннан Татарстанда 984 профилактика төркеме оештырылган. Полиция, җирле үзидарә вәкилләре, инструкторлардан торган төркем шәхси һәм күпкатлы йортларга кереп, янгын куркынычсызлыгы буенча профилактика чараларын искә төшерә. Шулар белән беррәттән, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы вәкилләре автоном янгын турында хәбәр итү җайланмаларын да урнаштыра.

– Без балалар белән бергә яшибез. Улым белән киленебезнең дүрт баласы бар, әле тагын киленнең энесен дә опекунлыкка алдылар. Шуңа күрә өч ел элек үк районнан килеп, янгын чыгуны хәбәр итә торган махсус җайланма урнаштырып киткәннәр иде. Файдаланырга туры килмәсен, әлбәттә, тик аның булып торуы да начар түгел, – диде Азнакай районында яшәүче газета укучыбыз Зәлия Мостафина.

Белгечләр әлеге җиһазларның аз гына төтен исе турында да кисәтергә сәләтле булуын әйтә. Бәла-каза ишек какканда, хәвеф сигналы кабына. Ут чыгу турында хәбәр бирүче җиһаз электр челтәренә тоташтырылмаган, ә аның көче бер елга кадәр җитә.

Бәхеткә, алар нәтиҗә дә күрсәтә. Вакытында көчле тавышны ишетеп, үз-үзләрен саклап калган кешеләр турында әледән-әле язып торабыз бит. Әйтик, сентябрьдә генә Арча районының Кызыл Яр авылында яшәүче 76 яшьлек хатын-кыз, нәкъ менә әлеге җайланманың тавышын ишетеп, йокыдан уяна һәм өйдән чыгарга өлгерә.

Гомумән алганда, 2016–2023 елларда килеп чыккан янгыннарның 108 очрагында өй хуҗаларын шул җайланмаларның көчле тавышы коткарып калган. Бу – 270 кешенең, шул исәптән 85 баланың гомере дигән сүз. Быел гына да шундый җиде очрак теркәлгән, сигез кешенең гомере саклап калынган.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе белгечләре аңлатуларынча, әлеге автоном җайланмалар күпбалалы гаиләләр, 70 яшьтән өлкәнрәк ялгыз, физик мөмкинлекләре чикле кешеләр яшәгән, балигъ булмаган балалар үстерүче имин булмаган һәм социаль куркыныч гаиләләргә урнаштырыла. Шулай итеп, 2016–2022 елларда Татарстанда 131969 йортка 397024 автоном җайланма куйганнар.

– Бу эшләр быел да тукталып тормады. Ел башыннан республикада 8 меңгә якын йортта 19212 җайланма урнаштырылды. Аларның 7 меңнән артыгы бюджет акчасына куелды. Мондый җиһазлар һәр йортта һәм фатирда урнаштырылса яхшы. Ташламалы категорияләргә бушлай куела, шулай ук кешеләр аларны үзләре дә алып урнаштыра ала. Аны теләсә кайсы кибеттән сатып алырга һәм урнаштырырга мөмкин. Бәяләре – 300–400 сум. Саклап калынган гомерләр турында уйласак, бу бик аз, – диде матбугат хезмәте җитәкчесе Александр Родыгин.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсенең янгынга каршы федераль хезмәтенең бүлек инженеры Зөлфәт Шәймуллин сүзләренчә, мондый җайланмалар һәр янгын сүндерү бүлекчәсенә берничә данә бирелә. Махсус билгеләнгән кешеләр аларны беренче чиратта күпбалалы, имин булмаган, өлкәннәр һәм авырулар яшәгән гаиләләргә тарата. Әгәр инде ул моңа кадәр урнаштырылган булса, батареясен алыштыралар.

– Мин озак еллар янгын сүндерүче булып эшләдем. Кызганыч, эш барышында төрле очракларны күрергә туры килде. Шуңа бәйле бер хәл исемдә калган. Өлкән яшьтәге әби белән бабайның йортында янгын чыккан. Бу турыда кисәтә торган җайланма куелган булса да, ремонт вакытында аны алып торган булганнар. Нәтиҗәдә әлеге пар һәлак булган иде. Әгәр әлеге җайланма булса, өлкәннәр исән дә калыр иде. Шуңа күрә мондый җайланманың чыннан да кирәклегенә шигем юк. Мин аларны үз йортыма да урнаштырдым. Балалар югалып калмасын өчен, барыбыз да өйдә вакытта җайланмаларны төрле бүлмәләргә куеп, кабызып, күнекмәләр ясатам. Башта барысын да яхшылап аңлатам, шуннан соң «имтихан» алам. Башка әти-әниләргә дә мондый дәресләр үткәрергә киңәш итәм, – диде Зөлфәт Шәймуллин.

Тик күпчелегебез куркынычсызлык турында уйлап бетерми, аңа салкын карый. Кемдер, минем белән мондый хәл килеп чыкмас, дип уйлап ялгыша. Хәтта яңа фатирларга урнаштырылган хәбәр итү җайланмаларын сүтеп алып куючылар да бар. Югыйсә бу беренче чиратта үзең һәм якыннарың өчен кирәк. Кызганыч, аяныч хәлләр еш очрый, ә ялкын телләре ялгышуны кичерми.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Түләүләр арта

Киләсе елда социаль түләүләр 7,5 процентка, яки быелгы инфляция күләмендә арттырылачак. Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов әйтүенчә, биредә сүз хезмәткә түләүнең минималь күләменә (МРОТ) бәйле булмаган социаль түләүләр турында бара. Ана капиталы, балалы гаиләләргә пособиеләр, аз керемлеләргә түләүләр 7,5 процентка үсәчәк, дигән сүз. Депутат сүзләренә караганда, киләсе елда инфляция күләме 8–8,5 процентка җитсә, февраль аенда һәм соңыннан социаль түләүләр тагын артачак.

Сүз уңаеннан, узган атнада Дума МРОТны киләсе ел башыннан 19242 сумга җиткерү турында законны беренче укылышта хуплады. Закон кабул ителсә, илдә 4,8 миллион кешенең хезмәт хакы артачак.

Яз күрсәтер

Татарстанда быел чәчелгән мәйданнарның 60 проценты чамасында уҗымнар тишелгән. Ләкин чәчүлекләрнең 40 проценты тирәсе начар хәлдә. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров әйтүенчә, республикада уҗым культуралары 550 мең гектар мәйданда (планлаштырылганнан 50 мең гектарга артыграк) чәчелгән. «Ләкин тишелмәү куркынычы бар. Гәрчә җылы һава вәгъдә ителсә дә. Һәрхәлдә, уҗымнарның торышы язын бик ачык күренәчәк», – ди министр.

Моңа кадәр авыл хезмәтчәннәре былтыр көз чәчелгән 50 мең гектарга якын уҗымны югалткан иде.

Урман үстерәбез

Быел «Урманнарны саклыйбыз» һәм «Хәтер бакчасы» бөтенроссия акцияләре кысасында Татарстан урманнарында 3,2 миллион агач үсентесе утыртылган. Урман хуҗалыгы министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, «Хәтер бакчасы» дүртенче тапкыр үткәрелеп, яз көне 1,2 миллион үсенте утыртылган.

Ә «Урманнарны саклыйбыз» кампаниясе чорында 2 миллион агач утыртылган. Әйтик, Казанның Куземетьево урманында 6 меңгә якын нарат утыртканнар. Акция Татарстанда 170 урында уздырылган.

Исегезгә төшерәбез: Татарстан җиренең 19,6 процентын урманнар биләп тора. 145 мең гектар мәйданны (территориянең 2 проценттан күбрәген) кырларны ышыклау полосалары тәшкил итә.

tatarstan.ru

Актуаль сорау

Бурыч – эче борыч

Суд приставлары тагын да яхшырак эшли башлаганмы, әллә бурыч йөген сөйрәгән кешенең аңы үзгәргәнме – быел узган ел белән чагыштырганда бурычлылардан 10 процентка күбрәк акча түләттерә алганнар. Бу хакта Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе җитәкчесе Әнвәр Закиров хәбәр итте. Сүз аз да түгел, күп тә түгел, 13 млрд 481 млн сум акча турында бара.

Түләмичә ярамый

13 млрд сумның «эче»нә кереп карыйк. Нәрсәләрдән тупланган бурыч соң бу? Акча санарга тотынганбыз икән, кисәтеп кую дөрес булыр: саннар шактый булачак.

Түләттерелгән бурычның гомуми суммасыннан 911 миллионы алимент түләү буенча бурычларга туры килә. 48 млн сумы – хезмәт хакын түләү буенча бурыч.

Әнвәр Закиров сүзләренчә, бурычлыларны административ җаваплылыкка гына түгел, җинаять җаваплылыгына да тарталар. Әйтик, 2023 елда 8901 әҗәтлегә – административ, 900енә җинаять җаваплылыгы ачысын татырга туры килгән.

Әнвәр Закиров сөйләвенчә, суд приставларына быел 2645405 эшне хәл итү бурычы йөкләнгән. Идарә

ru.freepik.com

җитәкчесе әйтүенчә, суд приставлары алимент түләттерүгә аерым игътибар бирәләр. Аларга карата закон кырыс, ди ул.

– 2311 алимент түләмәүчене административ, 882сен – җинаять җаваплылыгына тарттык. Әйе, аларга карата булган чаралар кырыс, әмма тәҗрибә күрсәткәнчә, әнә шулай гына алар бурычларын каплый, – диде Әнвәр Закиров.

ЮХИДИ штрафларын түләттерү буенча да эш тукталмый. Вакытында штрафларын түләмәгән «тимер ат» хуҗаларының эше еш кына суд приставлары кулына эләгә. Хәзер аларда үз чиратын көткән 211432 эш бар. Ел башыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозучылардан 405 миллион сумнан артык бурыч түләттергәннәр.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Дмитрий ВОРОНА, Федерация Советының Икътисадый сәясәт комитеты әгъзасы, Запорожье өлкәсеннән сенатор:

Запорожье өлкәсе – эре сәнәгать үзәге. Әмма хәрби хәрәкәтләр якын булу сәбәпле, күп кенә предприятиеләр тулы куәтенә эшли алмый. Шул ук вакытта төбәктә машина төзелешен, хәтта легендар «Запорожец»ны торгызу өчен барлык шартлар да бар. Ул заманча халык автомобиле булырга мөмкин.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ЭШ

Россиядә яшәүчеләрнең күпчелеге эш урынын алмаштырырга тели. Моның сәбәпләрен «Зарплата.ру» хезмәте ачыклаган.

79% >> стресс, арыганлык / 33% >> түбән хезмәт хакы

18% >> карьера үсеше юк

13% >> бик еш уза торган җыелышлар

12% >> җитәкчелек контроле

16% >> җитәкчедән канәгать булмау

Нормадан тайпылмый

Татарстанда ноябрьдә айлык уртача температура нормадан тайпылмас дип фаразлана. 2023/2024 елгы җылылык бирү чорына республикада һава температурасы фаразында шулай диелгән. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, көзнең соңгы аенда төбәктә айлык уртача температура нормасы –2,7 градус тәшкил итә.

Декабрьдә һәм киләсе елның гыйнварында да температураның нормага якын булуы фаразлана. Бу айлар өчен норма –8,9 градус һәм –10,9 градус. Февральдә исә айлык уртача температура нормадан (–10,7 градус) югарырак булыр дип уйланыла. Ә март аенда нормадан тайпылмавы (–4,2 градус) көтелә.

Бу көннәрдә җылыта. Көндез һава температурасы +13 градуска кадәр күтәрелергә мөмкин.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ГАЗ КИРӘГЕННӘН АРТЫК, ӘММА...

Дөньяда барган киеренкелекнең нигезендә энергия чыганаклары өчен тартыш ятуы берәүгә дә сер түгел. Көнбатыш һәрвакытта да нефтьле һәм газлы илләргә басым ясый, сугышны да шуларга каршы башлый. Углеводородлы төбәкләрдә киеренкелек көчәюгә, «кара алтын» һәм зәңгәр ягулык бәясе түшәмгә күтәрелә. Урта диңгездә АКШның очкыч йөртүче кораблар төркеме туплана башлаган икән, сәбәбе сер түгел: «кара алтын» державаларына һәм Төркиягә янау.

Әле яңа гына «Дуайт Д. Эйзенхауэр» авианосецы кораблары төркеме Гибралтар бугазы аша үтеп чыкты. Хәзер төбәктә АКШ-НАТОның 73 хәрби корабы тупланып килә. Су асты көймәләренең саны мәгълүм түгел. Соңгы 50 елда бер төбәктә бу кадәр көч тупланганы булмаган. Алар гадәттә бик зур сугышка әзерләнгәндә генә үз флотларын шулай массакүләм рәвештә эшкә җигәләр. Якын Көнчыгышта болай да тынычлык юк. Сишәмбегә каршы төндә Согуд Гәрәбстаны белән Йәмән гыйсьянчылары арасында төзелгән тынычлык килешүенең өзелү чигендә икәнен раслаган хәбәрләр килде. Чик буендагы Җизән шәһәрендә дүрт Гәрәбстан солдаты үтерелгән, гаскәрләр сугышчан әзерлек хәлендә.

Илләрнең хәрби бюджетлары чүпрә кебек кабара. Төркия киләсе елга хәрби бюджетын 2,5 тапкыр арттырачак. Америка быел хәрби разведка өчен генә дә 27,9 миллиард доллар акча тоткан. Чагыштырыгыз: Төркиянең быелгы хәрби бюджеты 25,2 миллиард доллар, ягъни АКШның разведка чыгымнарыннан да кимрәк. Германиянең оборона министры Борис Писториус Европада зур сугыш башлану куркынычы булуын һәм аңа әзерләнергә кирәклеген әйтте.

Сугыш карчыгаларының аваз салуы һәм көннән-көн ныграк кычкырулары зур кризис адымнарына бәйле. Европада рецессия башлану хәзер рәсми рәвештә танылды. Германия агымдагы елда нефть кулланыну кискен рәвештә кимětте. Кимү темпы буенча Пакъстаннан гына калышып, икенче урында тора. Европа Союзында барлык газ саклагычлар да тулы, сыекландырылган газ саклау өчен корабларны файдалана башладылар. Сугыш барган Украина хабларына ягулык тутыргалар. Якын Көнчыгыштагы киеренкелек сәбәпле, Катар газ экспортын туктата дигән ялган хәбәрләр мәгълүмат кырына чыгарылганга күрә генә, зәңгәр ягулык кыйммәт тора. Углеводородларның кирәгеннән артык булуы – җитештерү кимү билгесе. Тик бу проблема хәзерге финанс моделе шартларында хәл ителерлек түгел...

Россиядә

ӨЧЛӘТЕЛГӘН КРЕДИТ ҺӘМ БӘЯЛӘР

Россия халкы матди проблемаларын бурычка җыеп хәл итә. Бездә әлегә рецессия юк (шикелле дип әйтик инде). Хәрби сәнәгать комплексы үзе дә җитештерүне арттыра, чимал тармакларын да үз артыннан ияртә. Кредит алып, тормыш дәрәҗәсен күтәрергә тырышу өметле алым түгел, әлбәттә. Үзәк банк үзенең соңгы отчетында банклар һәм микрофинанс оешмаларыннан әҗәткә сораучылар санының 2023 елның беренче яртысында ике миллионга артып, 47 миллионга җиткән әйтә. Ипотекасы булган 10 миллион кешенең яртысының кимендә тагын бер бурычы белән дә тәэмин ителмәгән кредитлары бар. Үзәк банк бурычка акча җыючыларның уртача 2,8 кредиты булуын билгеләп. 2022 ел ахырында бу сан 2,6га тигез булган.

Финанс регуляторы 3 һәм аннан да артыграк кредиты булучылар санының 11,2 миллионга җитүен хәвефле сан дип бәяли (яртш ел эчендә сан 1,4 миллионга арткан). Һәр икенче ипотека кредиты 25 һәм аннан да артыграк елга бирелгән. Берни белән дә тәэмин ителмәгән кредитларның 61 проценты 4–5 ел вакытка алына. Ипотека алучыларның 6,2 проценты 100 мең сумнан зуррак күләмдә яңа бер кулланучылар кредиты ала икән. Үзәк банкта моны беренчел взнос өчен дип уйлыйлар.

Төп ставканы 15кә кадәр күтәрәч, ипотека алучылар саны берникадәр кимер дип фаразлана. Әмма күпчелек өстенлекле ипотека ала, аның проценты үзгәрешсез, аерманы хөкүмәт каплый. Финанс министрлыгы өстенлекле кредитны туктату идеясен алга сөрә. Хөкүмәт моңа риза түгел, чөнки төзелеш тармагы болай да җимерелү куркынычы алдында тора. Төп ставканы күтәрү бер кызык нәтиҗәгә китергән: кешеләр өстенлекле ипотека алалар да үз кулларындагы акчаны депозитка салалар икән. Депозитлар ярыйсы ук процент табышы бирә. Акча эшләүнең бу ысулын Үзәк банкта беләләр, әмма белеп, нидер кылырга җыенулары күренми.

Рәсми рәвештә, зур инфляция көтелә, дип шаулаcалар да, бәйсез «Ромир» холдингы өч ай рәттән инде төп товарлар бәясе үзгәрмәвен әйтә. Моны кешеләр кулында акча юклыкка бәйле дип саный. Өчәр һәм аннан да артыграк кредит түләүченең сатып алу сәләте ни дәрәҗәдә булуын аңлау кыен түгел. Болар, теләсә-теләмәсә дә, ихтыяҗларын кысарга мәҗбүр булалар. Керемнең яртысын, хәтта сиксән процентын бурыч түләргә тоткан гаилә бик иркен кылана алмый. Кредитларның чамадан тыш күп җыелуы инфляция темпларын киметүче факторга әйләнеп бара, диләр. Сүз, әлбәттә, көндәлек кирәкле киң куллану товарларына бәяләр үсешенең тукталы хакында гына бара. Бу юлларның авторы Татарстандагы азык-төлек бәяләрен тикшергәли, аларга бәяләр үсми диярлек. Кредит хисабына алына торган товар бәяләре куык булып кабаруын дәвам иттерә, билгеле.

ЫШАНЫЧЛЫ АДЫМНАР

Безнең бурыч – халыкның тормышын яхшырту. Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин Нурлат районына эшлекле сәфәре барышында шулай диде. Биредә ул «Бердәм Россия» көнә» проекты чараларында катнашты, «Заготпром» кооперативында булды, үсмерләргә паспортлар тапшырды, 50 ел бергә яшәүче гаилә парларын котлады һәм районның партия активы белән очрашты.

tatarstan.ru

Иң әлек «Грани» яшьләр үзәгендә паспортлар тапшыру тантанасы узды. Фәрит Мөхәммәтшин Нурлатта яшәүче егет-кызларга илнең, республика һәм районның лаеклы ватанпәрвәрләре булуларын теләде. Бу көнне 9 үсмер Фәрит Мөхәммәтшин кулыннан паспорт алды.

Районның ЗАГС бүлегендә исә Дәүләт Советы Рәисе район хакимияте башлыгы Дамир Ишкинеев белән «алтын юбилей»ларны – 50 ел бергә яшәүче гаилә парларын котлады. «Балаларыгыз һәм оныкларыгыз, тирәгездәге кешеләр өчен сез – үрнәк, – диде ул. – Республика һәм район файдасына хезмәтегез өчен рәхмәт, безнең барыбызны да сөендерәп, озак яшәгез!»

Шуннан соң Фәрит Мөхәммәтшин 1 нче урта мәктәптә өлкән сыйныф укучылары өчен Җиңү геройларына багышлап уздырылган ачык дәрестә катнашты.

Парламент башлыгы районның Халыклар дуслыгы йортында махсус операция зонасыннан кыска вакытлы ялга кайткан ир-егетләр, «Боевое братство» вәкилләре белән очрашты. «Безнең оешма гуманитар ярдәм җыю белән шөгыльләнә, – дип сөйләде «Боевое братство» отряды җитәкчесе Владимир Кузьмин. – Безнең бурыч – хәзерге вакытта махсус хәрби операция зонасындагы кешеләргә хәлдән килгәнчә ярдәм итү. «Бердәм Россия» партиясенең җирле бүлеге һәм район ярдәме белән егетләребез 16 машина гуманитар йөк озатты».

Соңыннан Фәрит Мөхәммәтшин район советының утырышлар залында партия һәм хуҗалык җитәкчеләре, депутатлар белән очрашты.

Дәүләт Советы Рәисе, очрашуны ачып, муниципаль берәмлекләрдә «Бердәм Россия» көннәре үткәрүнең инде күптән изге традициягә әйләнүен билгеләп үтте. «Бүген Нурлат районында мәдәниятне, төзелеш, мәгариф, сәламәтлек саклау өлкәләрен үстерү мәсьәләләре буенча мәйданчыклар эшләде, – диде ул. – Без асылда барлык юнәлешләрдә күпкырлы эшкә игътибар иттек. Нурлат районы ышанычлы төстә үсә».

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, «Бердәм Россия» көннәре кысасында уздырылучы чаралар, шул исәптән партия эшендә кимчелекләрне ачыклау мөмкинлеге бирә. «Безнең бурыч – халыкның тормышын яхшырту. Партия проектлары бу максатка ирешү өчен яхшы мөмкинлекләр бирә», – диде ул.

«Бердәм Россия»нең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре, киңәшмәдә катнашучыларны партия проектларын тормышка ашыру эшен көчәйтүгә өндәп, Нурлат районының алга таба да республика һәм партия программалары-проектларын тормышка ашыруда актив катнашачагына ышаныч белдерде.

Фәрит Мөхәммәтшин партиядәшләренә «Бердәм Россия»гә килгән һәрбер мөрәҗәгатьне игътибар үзәгенә алу зарурилыгын басым ясап әйтте.

Район хакимияте башлыгы Дамир Ишкинеев Нурлатта партия проектларын тормышка ашыру турында сөйләде. Аның әйтүенчә, соңгы елда район муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеш рейтингында 24 нче урынга күтәрелгән.

Нурлат районында «Бердәм Россия» көннәре кысасында партиянең төбәк һәм җирле иҗтимагый кабул итү бүлекләре белгечләре халыкны кабул итте, РКБ табиблары медицина тикшеренүләре оештырды, социаль тема һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча «түгәрәк өстәл»ләр, семинарлар үткәрелде.

БУРЫЧ – ӘЧЕ БОРЫЧ

Ахыры. Башы 1 нче биттә >

Суд приставларының да эше җиңел түгел. Әнә әледән-әле һөҗүм итүләр дә булып тора, ди. Әнвәр Закиров күптән түгел генә булган шундый вакыйганы да телгә алды.

– Еш булмаса да, суд приставларына һөҗүм итүләр очрый. Әле узган атнада гына Азнакай районында рейд чаралары кысасында булды бу хәл. Суд приставлары әҗәтле кешенең милек хәлләрен белергә дип, тикшерү белән чыккан иде. Бурычлы затның машинасы бар. Ул автомобилен тартып алуга бик каршы килде. Аңа карата җинаять эшен ачу мәсьәләсе карала, – диде идарә башлыгы. – Бер хезмәткәргә пычак белән кадаганнары да бар. Ярый ла ул махсус жилеттан иде. Кызганыч, мондый хәлләр булгалап тора. Шуңа күрә суд приставлары андый рейдларга хокук саклау органнары белән бергә йөри.

Әнвәр Закиров шунысын да искәртте: мондый адымга барсаң, закон алдында җавап бирәсен онытма. Моның өчен Россия Җинаять Кодексының 318, 319 нчы маддәләре бар.

Суд приставлары да мәгълүмати технологияләрне халык файдасына куллана башлаган. Әйтик, хәзер суд хәл иткәнне гамәлгә ашыруны йөкли торган башкарма документларны (исполнительный документ) электрон рәвештә генә дә тапшырып була. Бу замана таләбе генә түгел, тизрәк, нәтиҗәлерәк эшләү өчен мөмкинлек тә. Алга таба исә җавап көткән зат башкарма производствоның барышы, суд приставының процессуаль гамәлләре турында электрон рәвештә мәгълүмат алырга мөмкин. Шулай ук Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинет аша электрон рәвештә үтенечләр һәм мөрәҗәгатьләр җибәреп тә була.

Тагын бер яңалык: ел азагына алимент түләтү буенча консультацияләр санын арттырмакчылар. Актуаль булып калган мәсьәлә турында сөйләшү 3 ноябрьдән башлап һәр җомгада узачак. Әнвәр Закиров үзе дә кызыксындырган сорауларга җавап бирүдә катнашмакчы. «Бу формат үзенең кирәк булуын расласа, 2024 елда да консультацияләр атна саен дәвам итәчәк», – дип тә хәбәр итте Әнвәр Закиров.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЭШНЕҢ ИЯСЕ ЮК

Сәламәтлек

Илдәге табибларның эшен киметмәкчеләр. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы сәламәтлек сагында торган белгечләрне тавык чүпләп бетермәслек вак-төяк эшләрдән азат итеп, авыруларга игътибарны арттырмакчы. Табиб өстеннән төшкән бурычларны исә медицина белеме булмаган башка белгечләргә йөкләмәкчеләр.

Бу хакта Адыгея Республикасына эш сәфәре барышында Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко хәбәр итте. «Медицина тармагы алга китсен өчен, анда эшләүчләр санын арттырып кына калмыйча, алар өстенә өелгән бурычларны да киметергә – аларны башка кешеләргә тапшырырга кирәк», – дип белдергән иде министр.

Министрлык каршындагы Сәламәтлек саклауны оештыру һәм мәгълүматлаштыру үзәк фәнни-тикшеренү институты белгечләре бу уңайдан методик тәкъдим дә эшләгән. Аның авторлары фикеренчә, сәламәтлек саклау юнәлешендә хезмәт куйган һәркем – табибмы ул, фельдшер, шәфкать туташымы – үзенең төп вазыйфасын җиренә җиткереп, сыйфатлы итеп башкарырга тиеш. Ә моның өчен аларны, иң беренче чиратта, кәгазь боткасы кебек өстәмә эшләрдән азат итәргә кирәк.

– Хастаханәгә мөрәҗәгать итүчене иң беренче чиратта теркәү бүлмәсендә каршы алалар. Аларның белгечкә нинди гозер белән килүен ачыклау, авыру турында тулы мәгълүматны компьютерга теркәү, аны үзенә кирәкле табибка юллау эшен дә нәкъ менә бирәдә утыручылар башкарырга тиеш. Шәфкать туташлары исә укол ясау, система кую кебек эшләреннән тыш белешмә-юлламалар, табиб кушуы буенча даруга рецептлар да тутырырга бурычлы. Авыруның медицина кенәгәсеннән өземтә язып бирү, анализ һәм тикшерену нәтиҗәләрен кәгазьгә теркәү дә алар җаваплылыгында, – диелә документта.

Министрлык тарафыннан әзерләнгән яңалык гамәлгә керә калса, табиб өстендәге эшләрнең күбесе аның бүлмәсенә кергәнче үк башкарылачак. Әйтик, теркәү бүлегендә үк кешегә диагностик анкета тутырып, алга таба шәфкать туташы аның кан басымын, температурасын, буен, авырлыгын үлчәп, медицина картасына язарга тиеш булачак. Шул рәвешле табибка кергәндә инде ярты эш эшләнә. Больничный кәгазе, шифаханә картасы кебек документларны кильчәктә колл-үзәк белгечләренә тутырта башларга җыеналар.

Казанның 18 нче шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Регина Галиуллина да кәгазь боткасын табибларның үзәгенә үткән мәшәкатьләрнең берсе дип саный. Бу эшне бик теләп башка белгечкә тапшырырга риза ул.

– Бер авыруга билгеләнгән 15 минут эчендә табиб нәрсәгә генә өлгерсен?! Авыру белән сөйләшәсеңме, авыру тарихын өйрәнеп, диагноз куясыңмы, медицина картасын тутырасыңмы?! Авыруның документларын колл-үзәктә тутырсалар, яхшырак булыр иде. Анда да компьютерда эшли белгән, белемле кешеләр утыра бит. Димәк, аларга документларны курыкмыйча ышанып тапшырырга мөмкин, – ди табиб.

Ул, табибның авыруларга күбрәк игътибар бирүен теләсәк, заманча IT технологияләрне дә эшкә җигәргә кирәк, дип саный.

– Әйтик, табиб авыруны кабул итү барышын, тикшерену нәтиҗәләрен, диагнозларны аудиохәбәр рәвешендә язды рып, башка кеше шуны тыңлап, белгеч сүзләрен кәгазьгә теркәп бара ала бит. Күп кенә чит илләрдә, мисал өчен, Германиядә бүген киң кулланыла ул. Табиб авыру тарихын яздырып тора, ярдәмчесе шуны кәгазьгә теркәп бара. Тавышны автомат рәвештә кәгазьгә төшерә торган программа уйлап тапсалар да яхшы булыр иде, – ди табиб.

«Актион Медицина» сервисы оешмалары күптән түгел сәламәтлек саклау тармагында эшләүчеләр арасында бу яңалык уңаеннан сораштыру уздырырга да өлгергән. Анда 523 шәфкать туташы белән 356 табиб катнашкан. Нәтиҗәләре шактый кызыклы. Баксаң, шәфкать туташларының күбесе (63,7 процент) табиб башкарырга тиешле эшләрне алар җилкәсенә өяргә тырышуларына каршы икән. 18,9 проценты исә бу үзгәрешләрне хуплый, 7,3 проценты авырулар шәфкать туташына табибка ышанган кебек ышанмас дип шикләнә. Табиблар арасында, киресенчә, бу яңалыкны хуплаучылар күбрәк (62,3 процент). Аларның яртысы диярлек (46,2 процент) «күптән вакыт» дип белдерсә, 16,1 проценты: «Бездә бу яңалык күптән гамәлдә инде», – дип белдергән.

Күптән гамәлдә, дигәннән, бер белгечнең эшен башкаларга бүлеп тапшыру тәҗрибәсе шәхси медицина оешмаларында инде күптән кулланыла. 11 нче номерлы шәһәр балалар хастаханәсе табиб-терапевты, дәүләт дәвалау оешмаларында да бу үзгәрешкә күптән мохтаҗ, дип саный.

– Күп кенә шәхси медицина оешмаларында табибка керер алдыннан авыруның буен, гәүдә авырлыгын алдан үлчәү, больничный ачу кебек эшләр кабул итү бүлмәсендә башкарыла. Бу шулай булырга тиеш тә. Юкса, мондый вак-төяк эшләр кулны бик нык тота. Авыруны яхшылап тикшерергә дә вакыт калмый. Бер табиб берьюлы ике белгеч өчен эшләргә мәҗбүр булган хәзерге шартларда бу хәлне тагын да катлауландыра, – ди табиб.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«БҮГЕНГӘ ТӨП БУРЫЧ – БЮДЖЕТНЫ СЫЙФАТЛЫ ИТЕП ҮТӘҮ»

Татарстан Рәисе 9 октябрьдә Дәүләт Советына бюджет юлламасын кертте. 2 ноябрьдә республика бюджеты беренче укылышта каралачак. Татарстан Республикасы финанс министры Радик ГАЙЗАТУЛЛИН белән хәзерге вакытта тупланма бюджетның ничегрәк үтәлүе, 2024 елга һәм 2025–2026 еллар план чорына бюджетның социаль әһәмияте турында сөйләштек.

Керемнәр һәм чыгымнар

:: Радик Рәүфович, октябрь ахырында быел 9 ай эчендә бюджетны үтәүгә йомгак ясалды. Киләсе өч елга төзелгән бюджет проекты мәсьәләләренә күчкәнче, бюджетның бүген ничегрәк үтәлүе турында беләсе килә. Керемнәр Татарстан халкы алдындагы барлык социаль бурычларны үтәү мөмкинлеге бирәме?

– Үзем дә сүзне шуннан башлап җибәрү дөресрәк булыр дип уйлыйм. Чыннан да, шушы көннәрдә Министрлар Кабинетында узган республика киңәшмәсендә 9 айда республика тупланма бюджетын үтәү йомгаклары каралды, шулай ук калган айларга бурычлар билгеләнде.

Финанс министрлыгы – республика тормышының төрле өлкәләрендәге мәсьәләләр белән шөгыльләнүче оешма. Шуңа күрә соравыгызга җавапны саннардан башлыйм.

Быел 9 айда Татарстан тупланма бюджетының керем өлешенә 331,2 миллиард сум күләмендә салым һәм салым булмаган керемнәр алынды. Шул исәптән республика бюджетына – 283,7 миллиард сум, җирле бюджетларга – 47,5 миллиард сум.

Әйтергә кирәк, барлык төр бюджетларда керем өлешенең әйбәт кенә үтәлеп килүе күзәтелә. Тупланма бюджетның һәм республика бюджетының еллык күрсәткечләре – 79 процентка, җирле бюджетларныкы 78 процентка үтәлгән.

Республика бюджеты керемнәрендә төп өлешне, гадәттәгечә, предприятиеләр табышына салым һәм физик затларның керемнәренә салым (НДФЛ) алып тора. Аерым алганда, 9 ай эчендә табышка салым 133,2 миллиард сум тәшкил итте. Республика тупланма бюджетына 93,1 миллиард сум күләмендә НДФЛ керде.

Социаль бурычны үтәүгә килгәндә, аның республика Хөкүмәте, шулай ук Финанс министрлыгының өстенлекле бурычы булып торуын әйтеп үтәргә кирәк. Бу хакта республика киңәшмәсендәге чыгышымда сөйләдем һәм тагын бер тапкыр кабатлап үтәм. Агымдагы елның 9 аенда тупланма бюджет чыгымнары 353 миллиард сум тәшкил итте.

Шул рәвешле, узган елдан артып калып, агымдагы ел башына күчкән акча калдыгы һәм 9 айда алынган керемнәр бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакын тулысынча һәм үз вакытында түләү, барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларның планлаштырылган чыгымнарын җитәрлек күләмдә финанслау мөмкинлеге бирде.

Шул ук вакытта хезмәт хакы буенча «май указлары»н гамәлгә ашыруның бюджет чыгымнарын үтәүнең төп мәсьәләләреннән берсе булып торуын аерым искәртеп узарга кирәк. Әлеге указлар нигезендә, 2023 елда, республикадагы уртача хезмәт хакыннан чыгып, бюджет өлкәсенең аерым бер категориядәге хезмәткәрләренең эш хакы тиешле күрсәткечләргә җиткерелә.

Социаль юнәлеш

:: Татарстан Республикасы бюджеты – республика бюджеты системасының мөһим буыны. Аны булдыру чорында нәрсәләрне аерым билгеләп үтәр идегез?

– Башкарылган барлык эшкә күз салсак, шуны әйтергә мөмкин: бюджет проектын караганчы, Хөкүмәт, депутатлар, Финанс министрлыгы бюджет чыгымнарын киметү, нәтиҗәсен арттыру, республика икътисадына инвестицияләр җәлеп итү, кече һәм урта бизнеска ярдәм итү максатында аерым салымнар буенча ставкалар, ташламалар билгеләүгә юнәлдерелгән норматив актларны яңарту буенча тырышты.

Моннан тыш 2024 елга социаль-мәдәни өлкәнең барлык тармакларын финанс ягыннан тәэмин итү нормативлары тулысынча яңартылды. Ел ахырына кадәр Хөкүмәтнең 40 карарын һәм республиканың ике законын кабул итү бурычы куелды. Нәтиҗәләр бар. Бүгенгә норматив актлар асылда расланган инде, график үтәлә.

:: Радик Рәүфович, парламент тыңлауларында Татарстан Премьер-министры урынбасары – Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе Шамил Гафаров, 2024 елга республика бюджеты – социаль юнәлештә, дип билгеләп үтте. Бюджетның социаль юнәлеше нәрсәдә күренә?

– Чыгымнарда. Нәкъ менә шулар 2024–2026 елга төзелгән бюджетның социаль юнәлешле булуын тагын бер кат раслый.

Шуннан чыгып, бюджетлар чыгымнары турында сөйләүче төп тенденцияләрне телгә алып үтәсем килә. Беренче чиратта – өч ел эчендә иң кирәкле һәм социаль әһәмиятле чыгымнар бюджетта 84 процентка кадәр җиткерелә. Шул ук вакытта социаль өлкәгә чыгымнар күләменең һәр ел саен уртача 8 процентка артып барачагын күрәбез. Бу әле – агымдагы чыгымнар буенча гына.

Әйтик, социаль-мәдәни өлкәдә «Мәгариф» тармагына барыннан да күбрәк чыгымнар күздә тотылган. 2024 елда тупланма бюджетта чыгымнар күләме 138,8 миллиард сумга җитәчәк. 2026 елда чыгымнарны 168,8 миллиард сумга кадәр арттыру каралган.

Бу чыгымнарда укучылар саны арту, кадет интернатларында тәрбияләнүчеләрне тоту, йомгаклау аттестациясе уздыру өстәмә рәвештә исәпкә алынган. «Мәгариф» тармагы буенча республиканың кайбер социаль максатчан программалары да финансланыла. Болар – Татарстан Республикасында телләрне саклау һәм үстерү, балалар һәм яшьләр ялын оештыру, мәгариф оешмаларын капиталь төзекләндерү, ресурслар үзәкләрен булдыру, дәреслекләр сатып алу.

Шулай ук «Социаль сәясәт» тармагын алыйк. Биредә тупланма бюджет буенча гомуми чыгымнар 60,3 миллиард сум күләмендә фаразланыла. Бу чыгымнарда агымдагы елда инфляциягә карап арттырылган барлык социаль пособиеләр һәм түләүләр күздә тотылган.

Шулай ук Россия Президентының «май указлары» гамәлгә ашырыла башлаганнан бирле тупланма бюджетның хезмәткә түләү чыгымнары да елдан-ел арта. Гомумән, алар бюджетның башка чыгымнарына караганда тизрәк үсә. 2024 елда бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакы өлеше гомуми чыгымнарда 41,4% күләмендә билгеләнсә, 2026 елда барлык чыгымнарның яртысыннан күбрәген тәшкил итәчәк.

Моннан тыш бюджетта резерв фондларын булдыруга, капитал салуларга, илкүләм һәм төбәк проектларын тормышка ашыруга, бюджет учреждениеләренең мөлкәтенә салым һәм җиргә салым түләүгә, хезмәт хакын арттыруга, берничә ел дәвамында гамәлдә булып килүче социаль әһәмиятле республика чараларын финанслауга акча күздә тотылган. Үзара салым акчасын җәлеп итү нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл кылуга бюджетара трансфертлар бирүне, бакчачылык ширкәтләренә булышуны дәвам итү күздә тотыла.

Татарстан Республикасы тупланма бюджетында каралган чыгымнар республика һәм җирле хакимият органнарының барлык чыгым вәкаләтләрен финанслауны тәэмин итәчәк.

Инде килеп, шуны да билгеләп үтәсем килә: алдыбызда 2024–2026 еллар бюджетын үтәү буенча катлаулы, җаваплы бурычлар тора. Министрлыклар һәм муниципалитетлар, предприятиеләр һәм кешеләребез тотрыклы эшләгәндә, алдыбызга куелган бурычлар үтәләчәк.

Тотрыклы эшкә өмет

:: Радик Рәүфович, соңгы яңалыклардан күренгәнчә, Россия Хөкүмәте 12 төбәкнең, шул исәптән Татарстанның бюджет кредитлары буенча берникадәр бурычын кичерү турында боерык раслаган. Бүгенгә бюджет кредитлары буенча Татарстанның күпме әҗәте бар?

– Россия Хөкүмәтенең 21 октябрь, 2023 елгы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасының 7 миллиард 882 миллион сум күләмендәге бурычын гамәлдән алу күздә тотылган. Хәзерге вакытта республиканың федераль бюджет кредитлары буенча бурычы 111,0 миллиард сум тәшкил итә. Ул озак вакыт дәвамында түләнеләчәк.

:: Әңгәмәбез ахырында тагын бер сорау. Бүгенге катлаулы икътисадый вазгыять шартларында киләсе елда бюджетта каралган күрсәткечләр үтәлер дип уйлыйсызмы?

– Әйе, бюджетның катлаулы шартларда төзелүен танырга кирәк. Әлбәттә, хуҗалыкара элемтәләрнең өзелүе, логистиканың үзгәрүе, илебезгә халыкара санкцияләрнең кертелүе, башка тискәре күренешләр бюджетны үтәүгә тискәре йогынты ясаячак.

Шул ук вакытта бюджет проектында боларның барысы да исәпкә алынган. Ел дәвамында икътисадта кискен үзгәрешләр килеп чыкмаса, компанияләребез тотрыклы эшләсә, бюджет үтәләчәк.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Демидов** Юрий Иванович, хезмәт ветераны **Закирова** Әнисә Мансур кызы, җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Уразбаев** Рәфкать Шәфкать улы, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Хуҗиәхмәтов** Шамил Мохтар улы; 2023 ел сезоны чирәмдә хоккей буенча суперлига ир-ат командалары арасында Россия чемпионатында җиңү яулаганнары өчен «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторлары: һөҗүмче **Атаев** Артур Рөстәм улы, арадаш-сакчы **Луцевич** Иван Дмитриевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» (Иҗат берлеге) иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Галиуллин** Тәлгат Нәби улына **«Татарстан Республикасының Халык язучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Түбән Каманың 1 номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» акционер җәмгыяте автомобиль йөртүчесе **Акмалов** Булат Мияссәр улына, «Идея» инновация-җитештерү технопаркы» ябык акционер җәмгыяте автомобиль йөртүчесе **Фәйзрахманов** Хәйдәр Искәндәр улына, «Казанның 1 номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» акционер җәмгыяте автобус йөртүчесе **Школьников** Александр Викторовичка; «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Үзәк инфраструктура дирекциясе структур бүлекчәсе – Горький инфраструктура дирекциясе башлыгы урынбасары – Ижевск инфраструктура бүлеге башлыгы **Бәшәров** Разил Раил улына; «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Хәрәкәт белән идарә итү дирекциясе структур бүлекчәсе – Хәрәкәт белән идарә итү Горький дирекциясе структур бүлекчәсе – Юдино локомотивларны эксплуатацияләү депосының тепловоз машинисты **Мөхәммәтгалиев** Илшат Илгизәр улына, «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы баш механигы **Кулаков** Олег Александровичка, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе эксплуатация бүлеге автомобиль йөртүчесе **Баев** Назим Зәет улына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе автобазасы автомобильләрне төзекләндерү слесаре **Гурьянов** Дмитрий Викторовичка, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе эксплуатация бүлегенең кунакларны йөртү колоннасы автомобиль йөртүчесе **Маврин** Андрей Владимировичка, «Татавтодор» акционер җәмгыятенең юл төзелеше машиналары һәм транспорты бүлеге башлыгы **Порфирьев** Сергей Юрьевичка, «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Үзйөрешле вагоннар составы үзәк дирекциясе структур бүлекчәсе – Үзйөрешле вагоннар составы Горький дирекциясенең Казан үзйөрешле вагоннар депосы диспетчеры **Рубцов** Дмитрий Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы хезмәткәрләре: администратор **Акчурин** Айрат Ирек улына, тренер-аналитик **Тимашков** Тимур Игоревичка; «Динамо-Казан» чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторлары: **Ожерельев** Иван Сергеевичка, **Соболевский** Алексей Ивановичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе
СӘГЫЙТОВА Фәридә Муса кызы
вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Документлар идарәсе редактор экспертизасы һәм тәрҗемәләр бүлеге баш белгече Сәгыйтова Алсу Мәхмүт кызының авыр кайгысын уртаклаша.

Мәдәният дөньясында

ШИФАЛЫ МОҢ

Казанның «Сәйдәш» концертлар залында Татарстанның халык артисты Миңгол Галиевның әнә шул исемдә бик матур кичәсе узды. Миңгол Галиев өч сәгать ярым «Фантазия» кызлар джаз-оркестрына кушылып җырлады.

Ул көнне «Сәйдәш» залы моңга күмелде. Килеп керүчеләрне тамашачы үзе үк җырлап каршы алды. Арада баянын алып килгән абзый да бар иде. Татар халык көйләрен уйнап җибәрүгә, янына төркемләп кеше җыела. Ә инде аннары килгән тамашачының күңелен Миңгол абый сафландырды.

Концертта татар халык һәм классик җырлар башкарылды. 82 яшен тутырган Миңгол абыйның сәхнәдән кереп китмичә, бишәр җыр җырлавын тыңлап шаккаттык. Алып баручысын да туры китереп сайлаган ул. Алмаз Хәмзин бик урынлы гына шаяртып, үзе дә тамашаны ямьләндереп торды. Һәр җырның авторларын әйтеп барды. Дөрес, башка җырчыларныкы кебек билдән түбән шаяртулар, чинашулар, җырчының залга төшеп, кеше арасында кочаклашып йөрүләре булмаса да, Миңгол абыйны да яраткан тамашачысы ким-хур итмәде.

Сәхнәгә кочак-кочак чәчәкләр күтәргән кешеләр агылды. Кемдер рөхсәт сорап, җырчының битеннән дә үпте, күз яшьләре аша рәхмәт сүзләрен җиткерүчеләр дә булды. Миңгол абыйны чәчәкләргә генә түгел, матур сүзләргә, рәхмәт хатларына, данга күмделәр. Җырчыга Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы исеменнән Рәхмәт хаты, төрле елларда Казан федераль университеты белән берлектә музыка белгечләре әзерләүгә зур ярдәм күрсәтүе өчен, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры исеменнән дә Рәхмәт хаты тапшырылды.

Шулай ук ЮНЕСКОның халыкара бүләге – «Шәфкатьлелек» медале белән бүләкләнде ул. Медальне иясенә тарих фәннәре докторы, профессор, халыкара «Европа – Азия» академиясе президенты Энгель Таһиров тапшырды.

Сәхнәгә якташлары да күтәрелде. Мамадыш район мәдәният бүлеге җитәкчесе Степан Спиридонов Миңгол абыйга иң изге теләкләрен юллады. Хатыны Фәния апа белән озак еллар тигезлектә яшәргә язсын, диде ул. Фәния апа, дигәннән, бу урында аны да искә алу кирәктер. 82 яшендә дә егетләр кебек йөрүче Миңгол абыйның һәр уңышында аның да роле зур. Ник дигәндә, Фәния апа гел янәшә. Язмыш сынавын да икәү бергә күтәрә алган кешеләр алар. Әнә шуңа да кеше язмышлары чит түгел бу гаиләгә. Алар студентларына әти-әни җылысы бирә алганнар. Шәкертләре үзләре әнә шулай ди. Сәхнәгә чыккан һәрберсе сүзен рәхмәттән башлады.

– Миңгол абый безне үз баласыдай якын итә. Без аның моңына сокланабыз. Мондый җырчылар сирәк туа, – ди укучысы Альбина Кармышева.

Тамашачылар арасында шагыйрә Йолдыз Шәрәпова да бар иде. Ул, Миңгол абыйны Тукай премиясенә тәкъдим итәргә кирәк, диде.

– Миңгол абыебыз шушы яшендә сәхнә тота, мондый шәхесләрне бөек халык кына тудыра ала, шуны онытмасак иде! Үзебез дә, халкыбыз да аның кадерен белсәк иде. Аңа Тукай премиясен бирергә күптән вакыт, – диде ул. – Соңыннан үкенмәс өчен, бу ялгышны төзәтергә кирәк. Мондый үкенечләр күп булды инде.

«Татар-информ»

Галиевлар нәселендә моңлы җырчылар үсә. Әнә сәхнәгә әнисен җитәкләп менгән оныгы Аслан үсеп килә. 3 яше дә тулмаган малай саф татарча сөйләшә. Әле өмет бар. Аслан үсеп җиткәнче, Миңгол абыйның шәкертләре сәхнә тотар. Без аеруча Динар Шәймарданов, Рөстәм Егоровның чыгышларын ошаттык. Ни дисәң дә, күңел моңга сусаган. Тыныч кына татар көйләрен тыңлыйсы, аларны ишетеп, хозурланасы килгән икән.

Миңгол абый үзе дә, татар җырын, моның саклап калырга кирәк, ди.

– Җырларны үзгәртеп, заманчалаштырып башкаручылар күп. Татар моңын саклап, татар моңының үзенчәлекләрен белеп җырласак иде. Безнең композиторлар әсәрләре булсынмы, халык җырлары булсынмы – аны матур итеп башкара белү кирәк. Джаз-оркестр белән чыгыш ясавым юкка түгел. Татар җырларын тамашачыга оркестр ярдәмендә тапшырырга кирәк. Җанлы музыкада моң саклана.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Спорт кына түгел бу

ВАЛЕРИЯ ЗАХАРОВА:

«ИРЕМӘ РӘХМӘТ, ЙӨГЕРЕП ЯЛ ИТЕП АЛ, ДИ»

Казанда яшәүче Валерия ЗАХАРОВА һәрвакыт хәрәкәттә. Йөгерү белән мавыга ул. Узган ел гына шөгыльләнә башласа да, быел инде 10га якын төрле йөгерешләрдә катнашырга өлгергән. Аңардан яшәү рәвешенә әйләнгән спорт турында сораштык, йөгерү буенча киңәшләр алдык.

:: Спорт белән дуслык кайчан башланды?

– Минем үз матурлык студиям бар. Көннәрнең берендә тырнак ясап утырганда, клиент миңа: «Сиңа ябыгырга кирәк» – дип әйтмәсенме?! Ул вакытта миңа 26 яшь иде. Лизамны, беренче баламны тапкан чагым. Клиент кызның шундый сүзләре мине башта рәнҗетте, әмма аннары кинәт кенә мотивация уятты. Нәтиҗәдә мин тугыз килограмм авырлыктан котылдым. Әмма икенче балам Аняны тапканнан соң, тагын юанаеп киттем. Шулай якынча ике ел йөреп, фигураны тәртипкә китерү өчен, башта фитнес-клубка йөри башладым. Язын коронавирус аркасында бөтен кеше өйдә утырганда да, мин көн саен диярлек онлайн тренировкалар карап шөгыльләндем. Әйтергә кирәк, карантиннан соң да алты килограмм авырлыктан котылдым. Ә бүген инде спорт – минем яшәү рәвешем.

:: Ә йөгерү белән кайчан мавыга башладың?

– Ике ел элек булды бу хәл. Фитнес-клубка барганда игътибар иттем: «Миллениум» күперен япканнар. Йөгерү марафоны булган икән. Шул ук хәл көзен дә кабатланды. «Чаңгы шуам, тренажер залында күнегүләр ясыйм, йөзәм, велосипедта йөрим. Нишләп әле мин дә алар белән йөгермим?» – дигән уй туды миндә. Шулай итеп, йөгереп карарга ниятләдем. Узган ел фитнес-клубта Люда исемле кыз белән таныштым. Ул йөгерешләрдә катнаша икән. Йөгерә башлавыма ул этәргеч булды сыман. Беренче тапкыр 14,5 чакрым йөгергәнебезгә үзем дә ышанмадым. Кыскасы, Люда мине йөгерүдән рәхәтлек табарга өйрәтте, ягъни вакыт һәм дистанциягә игътибар итмәскә кушты. Унга якын йөгерештә катнаштым инде.

:: Йөгерү – чыгымлы шөгыльме?

– Профессиональ рәвештә йөгерәсе килә икән, әйтик, 42 чакрымлы марафонда, кыйбатлы махсус аяк киеме алырга кирәк. Ул аяк табанын, тезләрне саклый. Ә инде өч-биш чакрым йөгерә башлау өчен чыгымнар тотасы юк. Иң мөһиме – йөгерү техникасына игътибар итәргә һәм пульсны күзәтеп, уңайлы темпта йөгерергә. Үземә яңа максат куйдым: киләсе елның маенда кабат 21,1 чакрымлы Казан ярыммарафонында катнашырга. Йөгерергә, әзерләнергә мотивация булсын өчен, алдан ук махсус слот сатып алдым. Шуңа күрә кышын мин чаңгыда йөгереп һәм кимендә атнага бер тапкыр манежда әзерләнергә ниятлим. Әзерлексез генә бар көчкә йөгерергә ярамый – тезләр авырта башларга мөмкин.

:: Син әле «Гонка героев» ярышында да катнаштың. Махсус әзерләнмичә дип беләм.

– Бу хыялым да максатка әверелде. «Гонка героев»та катнашыр өчен, миңа команда кирәк иде. Аны табу җиңелләрдән түгел, әмма миңа бәхет елмайды. Әгәр дә син нәрсә булса да телисең икән, бу хакта сөйләргә кирәк! Шулай итеп, мин тренерым Ләйләгә үз хыялым турында әйттем. Катнашырга теләүчеләр әллә ни булмады. Быел булмас инде дип, мин дә өметемне өзгән идем. Әмма «Гонка героев»ка кушылырга насыйп булды. Сочида ял иткән чагым иде, шунда да ярышка әзерләндем: көн саен кимендә биш чакрым йөгердем. Казанга кайткач, икенче көнне үк ярышта катнаштым.

:: Ничек барысына да өлгерергә? Гаилә, балаларыңа вакыт каламы?

– Беренчедән, ирем Дениска зур рәхмәт! Ул 21 ел дәвамында гел янәшәмдә. Ирем кайвакыт: «Лера, ташла барысын да: ашарга әзерләмә, савыт-саба юма, үзебез эшләрбез, ә син йөгереп, ял итеп ал», – дип әйтә. Күпләр, йөгерү тезләргә зыян китерә дип, мине кире уйларга үгетләп карады. Әмма ирем, балаларым гел минем шөгылемне хуплады. Күптән түгел кечкенә кызым Аня да 300 метрлы йөгерештә катнашты әле.

Ә барысына да өлгерер өчен, берничә эшне бергә эшләргә өйрәнергә кирәк. Бер сәгать эчендә өч төрле ризык пешереп, савыт-саба юып һәм кызларның чәчләрен дә үрергә өлгерәсең икән ул. Әле мин яңадан «Гонка героев» ярышында, триатлонда катнашачакмын. Моннан тыш, гаиләм белән җәяүле маршрутларга, туристик походка чыгасы килә. Эльбрус тавына да менәргә исәп.

Диана КАРПОВА, КФУның 3 нче курс студенты

ҮЗ КЕШЕЛӘР

4 НОЯБРЬ – ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ КӨНЕ

Бәйрәм уңаеннан милли бергәлекне, телне, гореф-гадәт, мәдәниятне саклап калу – дус-тату яшәү серләре турында республикада яшәүче төрле милләт вәкилләренең фикерләрен сораштык.

Әхмәд ИШТИАК, Татарстан һәм Һиндстан арасында элемтәләрне үстерү үзәге җитәкчесе:

– Күптән түгел Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән Төркия Республикасы игълан ителүнең 100 еллыгына багышланган чарада катнаштык. Анда Татарстанда төрле милләтләрнең ничек итеп дус яшәве турында сөйләдек. Төрле диннәр, милләтләр бергәлеге булган Татарстан – дөнья күләмендә уникаль үрнәк. Бар да тәртиптә, бар да яхшы. Бу – республика җитәкчелегенең зирәк сәясәте нәтиҗәсе дип уйлыйм. Икътисад та алга бара. Республика шәһәрләрендә күпме Халыклар дуслыгы йортлары эшли бит. Бу – бердәмлек дигән сүз.

Татарстанда 3 меңләп һинд яши. Күбесе – студентлар. Милләттәшләрем саны елдан-ел артып тора. Студентлар Казан вузларына табиб, инженер, журналист һөнәрен үзләштерергә килә. Бер хөрмәтле табибыбыз Чүпрәле районы хастаханәсендә бүлек мөдире булып эшли.

Казандагы Халыклар дуслыгы йортында бүлекчәбез, Яшел Үзәндә мәдәни үзәгебез бар. Анда төрле чаралар, бәйрәмнәр уздырабыз. Якшәмбе мәктәбендә дәресләр күбрәк онлайн оештырыла.

Артур ПАШЕЕВ, Республика онкология үзәгенең анестезиолог-реаниматологы:

– «Ана теле» онлайн платформасы аша татарча өйрәндем. Тик кызганыч, быел аны яптылар. Яңадан ачсалар, татар телен өйрәнергә теләүчеләргә бик файдалы булыр иде.

Татарча сүзләрне дөрес әйтәмме, юкмы? Бу турыда татарча белүче хезмәттәшләремнән гел сорый идем. Беркайчан да, аптыратма әле, димәделәр. Эштән кайткач, көн саен 30 минут татарча өйрәндем. Татар телен белгәч, әби-бабайлар белән рәхәтләнеп сөйләшәм хәзер. Хатыным Алия – ярымтатар (*көлә*). Өйдә аның белән русча сөйләшәбез, эштә татарча аралашырга тырышам. Төркиядән студентлар килгән иде. Алар белән дә татарча аңлаштык. Татар мәдәнияте белән кызыксынам. Интернеттан татар спектакльләре, фильмнар карыйм. Татарстанда яшәгәч, татарча белергә кирәк дип саныйм.

Бейшенбек МУКАНБЕТОВ, Татарстанда кыргызлар милли-мәдәни оешмасы җитәкчесе:

– Татарстанда кыргызлар саны 12 меңгә якын. Казанга кардәшләремнең күбесе сезонлы эшләргә килә. Алар «Тура» базарында сату итә, автобуслар йөртә, төзелештә хезмәт куя.

Татарстанда яшәү рәхәт. Бу – минем икенче Ватаным. Казанга килүемә – 40 ел. Хатыным – татар. Ул – Кайбыч районының Борындык авылыннан. Ике ул тәрбиялибез. Өйдә татар, рус, кыргыз телләрендә сөйләшәбез. Милли ризыклар пешерәбез, гореф-гадәтләрне саклыйбыз. Елга ике тапкыр туган якка кайтырга тырышам.

Якшәмбе мәктәбенә 20–25 бала йөри. Традицияләр дә, бәйрәмнәребез дә күп безнең. Ат чабышлары, дини һәм балаларны сөннәткә утырту кебек гаилә бәйрәмнәрен дә үткәрәбез. Бала беренче адымын атлаган көнне корбан чалабыз, бишбармак пешерәбез. Бергә җыелышырга сәбәпләр күп, кыскасы.

Айсылу ЛОТФУЛЛИНА, «Иң яхшы туган тел һәм әдәбият укытучысы – 2023» бөтенроссия конкурсының тәрбиячеләргә кагылышлы номинациясендә җиңүче:

– Максат нинди – нәтиҗә шундый! 2023 ел Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы буларак игълан ителү уңаеннан, телгә, мәдәниятка игътибар артты, бик күп чаралар үткәрелде. Тамчыдан күл җыела, диләр. Бу өлкәдәге барлык чаралар да телгә уңай караш, ихтыяҗны арттыра. Әлеге чаралар дәвамлы булсын иде дигән теләктә калам.

Балаларга килгәндә, тел кызык, мавыктыргыч булса, алар рәхәтләнеп өйрәнә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен бу аеруча актуаль. Уен аша, балаларның ихтыяҗын, тормыш күзаллавын исәпкә алып төзелгән дәресләр татлы «җимеш»ләрен бирә. Телгә кагылышлы бәйге-бәйрәмнәрнең еш оештырылуы да уңай нәтиҗәләргә китерә.

Сэсэгма БУБЕЕВА, бурятларның Казандагы милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе:

– Заман үзгәрә. Менә шул вакытта үз милләтеңне саклап калу бик мөһим. Уен кагыйдәләре үзгәрсә дә, борынгы әби-бабайлардан калган рухи байлык, мирас һәрвакыт яши. Милли җырлар, биюләр, халык иҗаты аша телне саклап мөмкинлеге бар. Якшәмбе мәктәбендә 15 бала бурятча өйрәнә.

Казанда үзебезне өебездәге кебек хис итәбез. «Татарстанда бурятларның гадилеге, Мәскәүнең инфраструктурасы бар», – дип әйтергә яратам мин. Монда күченеп килүемә – 12 ел. Татарстанда бурятларның саны 200гә якын. Башта ун гына булганбыз. Ишәябез!

Виталий АГАПОВ, Татарстанның халык артисты, Татарстан халыклары ассамблеясының Чаллыдагы филиалы җитәкчесе:

– Чаллыда 86дан артык милләт вәкиле яши. КамАЗ төзелгәндә, бу сан 143 булган. «Чишмә» Халыклар дуслыгы йортында 22 милләтнең үз оешмасы бар. Туган телләр, гореф-гадәтләр, йолаларны саклап, киләчәккә җиткерү өчен, төрле бәйрәмнәр, чаралар уздырабыз. Мин – Чаллыдагы керәшеннәр җәмгыяте җитәкчесе дә әле. Автокалада халык санын алу нәтиҗәләре буенча 6 мең керәшен яши. Әмма бу сан күпкә артыграк дип саныйбыз. Без – актив эшләүче диаспораларның берсе. Якшәмбе мәктәбебез эшли, керәшеннәрнең музее бар. «Нардуган», «Питрау» бәйрәмнәрен утыз елдан артык уздырабыз инде. Без төрки халыклар төркеменә керәбез. Мин: «Телебез татар икән, төбебез татар», – дип тә әйтеп җибәрәм.

Халыкларны бөек яки кечкенә дип бүләргә ярамый. Һәр халыкның үз гореф-гадәтләре, йоласы бар. Үрнәк алырлык нәрсәләр күп. Тик нинди халык булуга карамастан, үз гореф-гадәтләрең белән чит йортка кереп, тәртип урнаштырырга кирәкми. Илеңнән кубып, Татарстанга килгәнсең икән, мондагы кагыйдәләрне истә тотып, үз йолаңны белеп, халык белән бергә яшәргә тиешсең. Әгәр үз тәртипләреңне урнаштырасың икән, бу гомер буе шул җирлектә яшәүче халыкка ошамаячак.

Сәрия МИФТАХОВА

tatarstan.ru

МИЛЛӘТ НИГЕЗЕ

ТАТАРСТАНДА МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫНА ЙОМГАК ЯСАЯЧАКЛАР

Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында республикада 500дән артык чара узган. Аның кайсылары аеруча истә калды? Елга куелган максатларга ирешелдеме?

«Татар-информ»да узган матбугат очрашуында үтеп баручы елга нәтиҗә ясадылар.

Милли бәйрәмнәр, концертлар, бәйгеләр, күргәзмәләр, интерактив проектлар. Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы, дөрестән дә, чараларга бай булды. Елның төп вакыйгалары турында Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин сөйләде.

– Бу ел безнең өчен бик әһәмиятле һәм җаваплы булды. Республика күләмендә 500дән артык зур чара узды. Быел алар аеруча тирән мәгънәгә ия. Чөнки безнең гореф-гадәт – динебезнең, милләтебезнең нигезе. Киләсе елларда да бу эшебезне дәвам итәрбез, – диде министр урынбасары.

Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы Халыклар бердәмлеге көнен үткәрү кысасында 3 ноябрьдә «Казан Экспо» залында зур чара белән төгәлләнәчәк. Анда 2500дән артык кунак көтелә. Бөтен республикадан 1000нән артык иҗади төркем, ансамбльләр катнашачак.

Быел республикада узган милли бәйрәмнәрнең интерактив күргәзмәсе «Казан Экспо»да узачак бәйрәмнең төп композициясе булачак.

Татарстан Халыклар дуслыгы йорты да «Казан Экспо»да узачак чарага шактый бай программа әзерләгән. Аның директоры Тимур Кадыйров сүзләренә караганда, кунаклар өчен белем бирү семинарлары, этнографик диктант уздырылачак, республикада яшәүче халыкларның мәдәниятләре, традицион һөнәрләре күргәзмәсе, «Безнең йорт – Татарстан» республика этномәдәни фестиваленең концерты тәкъдим ителәчәк.

Татар мәдәни ресурс үзәге директоры Алсу Мифтахова «Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурсы кысасындагы концертларның аншлаг белән узуын әйтте. «Бәйгедә республиканың 43 районы катнашты. Һәр район үзенчәлеген чагылдырырга тырышты. Концертларда урыннар җитмәде хәтта», – диде ул.

Чарада Татарстанның чигелгән картасын да тәкъдим итәчәкләр. Аны эшләүгә 150дән артык кеше җәлеп ителгән. Шулай ук елның якты вакыйгаларының берсе – Болгарда узган «Яңарыш: Эпос заманча укылышта» фестивале. Татарстан халкы һәм республика кунаклары җиде көн дәвамында Болгарда урта гасыр ярминкәсе мохитенә чумды, дөнья халыклары эпослары мотивлары буенча спектакльләр карады.

– Эшкә нокта куелмады, киләсе елда да шушы юнәлешне дәвам иттерәчәкбез, – диде Алсу Мифтахова.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13584 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 348

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+